**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17,с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
05, 0 2. 2019

КАРАР
___

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 декабрендәге 838 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Актаныш муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге 763 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районын Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 декабрендәге 838 номерлы карары белән расланган «2015 - 2020 елларга Актаныш муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе                                        И.Ш.Бариев

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

1.1. «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба - Программа) исемендә, «2015-2020» саннарын «2015 - 2021 » саннарына алмаштырырга; Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2015-2020» саннарын «2015-2021» саннарына алмаштырырга «Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2015-2020» саннарын «2015-2021» санына алмаштырырга.

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>Программаны ел һәм чыганакларга бүлеп финанслау күләмнәре</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына 330 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сумнарда)<br>
<table>
<tr><th>Ел</th><th>ТР Актаныш муниципаль районының җирле бюджеты акчалары</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>47,5</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>47,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>40,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>47 5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>47,5</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>50 о</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>330,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
</table>

Программаның 3 бүлегенең сигезенче абзацында «2015 - 2020» саннарын «2015 - 2021» саннарына алмаштырырга»;

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасының 5 һәм 6 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).